дога шунда ук Аллаһы хозурына ирешә икән.

Тагын шуңа игътибар итик - Аллаһы белән элемтә кылу авыр түгел. Моның өчен арадашчы да, техник чаралар да кирәкми. Бары тик адәм баласының күңеле саф, ниятләре изге булырга тиеш. Шул очракта без барыбыз да түбәнчелек белән Аллаһыга мөрәҗәгать итә алабыз.

Аллаһы адәм баласында була торган тәкәбберлек сыйфатын сөйми һәм бу хакта Коръәндә катгый кисәтә: *«Раббыгыз: «Миңа дога кылыгыз, сезгә җавап бирермен! Хакыйкатьтә, Миңа гыйбадәт кылудан тәкәбберләнгәннәр – алар җәһәннәмгә кимсетелгән килеш керәчәкләр!» – дип әйтте»* («Әл-Гафир» сүрәсе, 60 нчы аять).

Шулай ук Аллаһы Тәгаләгә Аңа хас булмаган, ят яки бозып әйтелгән исемнәр белән ялвару дөрес түгелдер. Аллаһы Тәгаләгә Коръәндә булмаган яки Мөхәммәд галәйһиссәләм яисә башка пәйгамбәрләр тарафыннан искә алынмаган исемнәрдән башкалары белән эндәшү гөнаһ булыр: *«Аллаһының гүзәл исемнәре бар һәм алар белән Аңа ялварыгыз, Аның исемнәрен таркатучыларны калдырыгыз. Алар кылган гамәлләренә карата җәзасын алырлар!»* («Әл-Әгъраф» сүрәсе, 180 нче аять).

Пәйгамбәребез хәдисе: *«Өч төрле кешенең догасы кабул булуында шик юк: атаның балаларына кылган догасы, мосафирның һәм мәзлүмнең догасы».*

Әлеге хәдистән аңлашылганча, бу өч кешенең изге догаларын өмет итеп, яман сүзләреннән аеруча нык саклану кирәк.

Коръәндә килгән кайбер дога үрнәкләре:

*«Раббыбыз! Үзебезне һәм безнең нәселебезне үз-үзләрен Сиңа тапшыручылардан итсәң иде. Безгә гыйбадәт йолаларын күрсәтсәнә! Тәүбәләребезне кабул итсәнә! Хакыйкатьтә, Син - тәүбәләрне кабул итүче, рәхимле»* («Бәкара» сүрәсе, 128 нче аять).

*«Раббыбыз! Әгәр без онытткан булсак яки хата кылган булсак, безләрне ачуланма! Раббыбыз! Бездән алдан килгәннәргә йөкләгән шикелле безләргә дә авыр йөк йөкләмәсәнә! Раббыбыз! Безнең көчебездән килмәгәнне өстебезгә йөкләмәсәнә! Гафу ит безне һәм ярлыкауга ирештер безне һәм безне кичерсәнә!»* («Бәкара» сүрәсе, 286нчы аять).

*(“Татар дини календаре”ннан)*

# һәрнәрсәнең парлы булуы – могҗиза

Аллаһы Коръәндә: *«һәр нәрсәне: җир үстергән үсемлекләрне, кешеләрне һәм кешеләр белми торган нәрсәләрне парлы итеп бар итүче Аллаһы һәр кимчелектән пакьтер»* (Йә Син: 36).

Бу аятьтә «әзуәҗ» сүзе кулланыла. Бу сүз берничә мәгънәгә ия:

1. Ир һәм хатын җенесеннән булган нәрсәләр.
2. Бер-берсенә капма-каршы булган нәрсәләр (антонимнар), мәсәлән, ак-кара, эссе-суык, изгелек-явызлык, авырлык-җиңеллек, көн-төн һ.б.
3. Бер-берсенә пар булган нәрсәләр: мәсәлән, ике пар канат, ике аяк, ике кул, ике күз һ.б.

Без бернинди авырлыксыз бу дөньяда һәрнәрсәнең, парлы, бер-берсенә капма-каршылыклар белән бар ителгәнен күрәбез. Хәтта кешенең баш мие дә ике ярымшардан тора. Шуңа да карамастан, алар бер бөтенне тәшкил итәләр. Хәтта утның януы өчен дә плюс белән минусның булуы кирәк.

Аллаһы бу аятьтә һәр нәрсәне һәм хәтта кешеләр белмәгән нәрсәләрне дә парлы, ирле-хатынлы һәм бер-берсенә капма-каршы итеп бар итүе хакында безгә хәбәр итә. Аллаһы бу галәмдә барлык нәрсәләрне төрле-төрле, парлы итеп бар итсә дә, Ул Үзе бер ялгызы, Аның пары да, мисалы да, тиңе дә юктыр. Ул болардан бөек һәм пакьтер.

1933 елда квантовая физика фәненә нигез салучы физик Поль Дирак табигатьтә барлык нәрсәләрнең дә парлы булулары хакында ачыш ясый. Бу ачышы өчен ул Нобель премиясенә ия була. Ачыш «Аннигиляция һәм парларның барлыкка килүе» исемен ала. Бу ачышта ул һәрбер әйбернең аннан үзгәре булган каршы әйбере (антивеществосы) барлыгын исбатлый. Мәсәлән, электроннарның тискәре зарядка ия булучы антивеществосы, уңай зарядка ия булган протоннары бар. Галәмдәге бөтен асыл кисәкчеләрнең каршылыклы кисәкчеләре бар. Антивещество да асыл веществоның массасына ия, ләкин тискәре зарядлар белән. Материя белән каршы материя катышу сәбәпле, аларның тискәре зарядлары да кушыла һәм шул сәбәпле энергия барлыкка килә.

Коръән җиргә 7 нче гасырда иңдерелде. Кешеләрнең әле бу хакта бернинди дә белемнәре юк иде. Әмма аятьләрдә галәмдә барлык нәрсәләрнең дә парлы икәнлеге хакында ачыктан-ачык әйтелә.

### Үсемлекләрнең парлы булулары

Ботаниклар үсемлекләрнең ирле-хатынлы булулары хакында 100 ел элек кенә белделәр, Коръәндә бу хакта 1400 ел элек инде хәбәр ителгән иде: *«Ул Аллаһы күкләрне, күргәнегезчә, бернинди терәүсез бар итте һәм җиргә тауларны урнаштырды, сезне тетрәтмәсен өчен, һәм җир йөзенә төрле җан ияләрен таратты. Без күктән яңгыр яудырып, һәрбер ирле-хатынлы, күркәм үсемлекләрне үстердек»* (Локман: 10). Яки башка аятьтә: *«Ул сезнең өчен җирне бишек кебек бар итте һәм анда сезгә юллар җәйде*





*һәм күктән яңгыр яудырды. Шуның белән без төрле-төрле, ирле-хатынлы үсемлекләрне үстердек»* (Та-һә: 53).

Үсемлекләргә килгәндә дә, алар дөньяда бик күптөрле һәм шуңа да галимнәр аларны төрле гаиләләргә, төрләргә бүлделәр. Бүләрлек тә, галимнәрнең санавы буенча, үсемлекләрнең генә саны җир йөзендә 400 меңгә җитә, ә хайваннарның төрләре миллионнан арта.

Белгәнебезчә, җимешләр өлгергәнче, алар башта чәчәк ата, ә чәчәкләр ата яки ана чәчәккә аерыла. Ата чәчәкләрнең серкәләре ана чәчәкләргә ирешкәннән соң гына, ана чәчәкләр җимешкә әйләнә башлыйлар. Пәйгамбәребез дә Мәккәдән Мәдинәгә күченеп килгәч, Мәдинә халкының хөрмә агачларын бер-берсенә бөгеп серкәлендергәнен күрде һәм, гаҗәпләнеп: «Сез ни эшлисез»? – дип сорады. Алар: «Әй, Аллаһының рәсүле! Әгәр дә без болай эшләмәсәк, безнең уңышыбыз булмаячак», – дип җавап бирделәр.

Хәзер исбат ителгәнчә, серкәне кабул итү очраклы рәвештә генә түгел икән. Күп үсемлекләр һавадан мөмкин кадәр күбрәк серкәне кабул итү өчен җайлаштырылганнар. Кайбер үсемлекләр моның өчен ябыштыручы сыекча бүлеп чыгаралар яки серкәләрне тотып алу өчен мыекларын чыгаралар.

Мәсәлән, нарат агачын алыйк. Агачның өске өлешендә ана күркәләр, ә астарак бер төркем ата күркәләр булып урнашканнар. Шулай урнашу сәбәпле, агач үз-үзен серкәли алмый. Әмма җил сәбәпле ата чәчәкләрнең серкәләре күрше агачның ана чәчәкләрен серкәли.

Әгәр дә инде киресенчә, ата чәчәкләр өстә булып, ана чәчәкләр аста булсалар, өстәге ата серкәләр төшеп ана чәчәкләрне серкәләндерәчәк һәм нәтиҗәдә зәгыйфь, көчсез буын барлыкка киләчәк, дип әйтә галимнәр.

Әгәр парлылык булмаса, бу дөньяда үрчү һәм арту булмас иде. Галимнәрнең ачышы белән Коръән аятьләренең туры килүе Коръәннең Аллаһы сүзләре икәненә дәлил.

Бу Китап үзе могҗиза, һәм ул мәңге шулай булачак. Аллаһы әйтте: *«Без аларга бу галәмдә һәм үзләрендә дәлилләр һәм үзләрендә дәлилләр күрсәтербез, хәтта бу Коръән аларга хак икәне ачыкланганчы...»* (“Фүссыйләт”, 53).

### Хатын - ирнең пары

Аллаһы үзенең мәрхәмәтеннән без, кешеләрне, дә ирле-хатынлы итеп бар итте. Аллаһы бу хакта: *«Аллаһының кодрәтенә дәлил буларак, Ул сезнең өчен үзегездән хатыннар бар итте, алардан тынычлык табуыгыз өчен. Шуның белән сезнең арагызга мәхәббәт һәм мәрхәмәт салды. Аллаһының бу эшләрендә фикерли белгән кешеләр өчен гыйбрәтләр бардыр»* (“Рум”, 21).

Ир белән хатынның никахлашуы сәбәпле, аларның араларында бер-берсенә мәхәббәт һәм мәрхәмәтлек барлыкка килә. Аларның бергә булулары белән күңелләре тынычлана һәм бер-берсеннән канәгатьлек табалар.

Никахның иң беренче максаты шушыдыр. Шушы мәхәббәт һәм мәрхәмәт эчендә алар балалар үстереп тәрбиялиләр һәм шуның белән бер-берсенә зур файда китерәләр, җәмгыятьне ныгыталар. Фикерләгән кеше өчен монда зур гыйбрәтләр бардыр. Әмма парларның динсез һәм гыйлемсез һәм хикмәтсез булулары сәбәпле, алар Аллаһыдан килгән мәхәббәтне сүндерәләр, мәрхәмәтле дошманлыкка алыштыралар. Шулай итеп, гаиләләр таркала, балалар ятим калалар. Аллаһы һәр пар арасына мәхәббәтен дә, мәрхәмәтен дә сала, бу мәхәббәтне саклау һәм ныгыту – ир белән хатынның вазифасы.

Әле табигатьнең ачылмаган серләре күп булса да, һәрбер әйбернең парлы булуы хакында ачыш мәгълүм.

**Марат хәзрәт СӘЙФЕТДИНОВ.**

*(“Иман” газетасыннан)*

# Аллаһы котылу бирсен дисәгез

Коръән-Кәримдә әйтелгән: *“Ий, иман китереп инанучылар! Әгәр билгеле бер вакытта бурыч алу-бирү белән шөгыльләнсәгез, аны язып куегыз! Кятиб кеше моны арагызда гаделлек белән язып куйсын. Һичбер кятиб Аллаһы үзенә өйрәткән кебек язып куюдан баш тартмасын. Ул язып торсын, өстенә бурыч алучы исә әйтеп торсын. Аллаһыдан ул курыксын, анда Һичбер нәрсәне дә киметмәсен генә!”* (“Бәкара”, 282).

Ислам динендә садака бирүдән дә бурычка бирүнең савабы күбрәк санала, чөнки садака һәм хәерләр ихтыяри рәвештә мохтаҗ һәм мохтаҗ булмаганнарга да эләгә. Әмма бурыч акчасы фәкать мохтаҗ кешеләргә генә бирелә. Бурычка биреп торуның өстенлеге турында күп кенә хәдисләрдә әйтелә. *“Кем ки кыямәт көненең кыенлыкларыннан Аллаһы котылу бирсен дисә, бурычка биреп, шул бурычны түләүне үти алмаучыга түләү вакытын озайттырсын яки бөтенләй бурычны кичерсен”* (Мөслим риваяте).

*“Кем ки фәкыйрьнең бурычын түләү вакытын озайтса, күләгә булмаган көндә (кыямәттә) Аллаһы Тәгалә аңа күләгә насыйп итәр”* (Мөслим риваяте).

*“Кайтару нияте белән бурыч алган кешенең бурычын Аллаһы кайтара. Кайтармау нияте белән бурыч алган кешенең байлыгын Аллаһы юк итә”* (Бохари риваяте). *“Түли алырлык хәлдә булып та бурычны бирмәү - золымдыр”* (Бохари һәм Мөслимәдә китерелә).

“Пәйгамбәребез с. бер кешедән бер яшьлек дөяне бурычка алган иде. Бераз вакыт үткәч, ул килеп Рәсүлуллаһка с. авыр сүзләр әйтеп, бурычны кайтаруны таләп итә башлады. Моңа ачуы чыккан сәхабәләр аны кыйнамакчы булдылар. Шунда Пәйгамбәребез аларны тыеп: “Дөрес хакын хаклаучының хакы бардыр. Аңа бер яшьлек дөя биреп озатыгыз”, - диде.

Сәхабәләр бер яшьлек дөя таба алмагач, Рәсүлулла с. зуррак дөяне биреп җибәрүгә әмер бирде һәм әйтте: *“Бурычны яхшырак үтәүчеләр сезнең арада иң яхшыларыгыздыр”* (Бохари һәм Мөслимдә китерелә).

**Вәлиулла хәзрәт ЯГЪКУБ.**

*(“Иман” газетасыннан)*